

## Ишниязова Сирень Фәрдус кызы

**Ишниязова Сирень Фәрдус кызы** 1967 елның 16 нчы сентябрендә Алексеевск районы Урманасты Шынталы авылында туа.1974 елда беренче класска укырга керә.1982 елда сигезьеллык мәктәпне уңышлы тәмамлап, Түбән Кама педагогия училищесына укырга керә.Училищены бик яхшы билгеләренә тәмамлап туган авылы мәктәбенә эшкә кайта. Математика укыту белән бергә, пионервожатый да булып эшли. Ул тиз арада балалар белән уртак тел таба.

**Ишниязова Сирень сөйләгәннәрдән**

***-Пионерга кергән көнегезне хәтерлисезме?***

- Их, кызыл галстуклы ул балачак! Быргы, барабан тавышлары, ялкынлы җырлар, киләчәк турында матур әкиятләр...

Минем балачагым да нәкъ шул чорның матур үрнәге булган пионер, комсомол оешмалары чәчәк аткан вакытка туры килде. Пионерга кергән көнем бүгенгедәй хәтеремдә. Беребездән беребез тырышып тантаналы вәгъдә бирдек, пионер законнарын әйттек, пионерлар турында шигырь юллары сөйләдек. Менә безгә кызыл галстуклар бәйләделәр. Миңа галстукны Вафина Нәзирә бәйләде. Галстук белән фотога да төштем.

Шунысы хәтердә калган: өйгә кайтканда, ярты юлга җиткәч,сумканы җиргә куеп,( 22 апрель бит, җир әле кипмәгән иде) галстугымны куртка өстеннән чыгарып куйдым.

***-Пионервожатый булып эшләгән елларыгыз турында ниләр әйтә аласыз?***

Үзебезнең мәктәпнең пионерлары белән бик күңелле, файдалы эшләр башкардык. Дружина сборы, отряд сборлары үткәрә идек.Сбор – ул җыен дигән сүз. Димәк, отрядның җыелып сөйләшүе, киңәшүе, мероприятие үткәрүе, экскурсия, походка баруы, тематик кичә уздыруы – болар барысы да җыен, ягъни сбор була. Май аенда мәктәптә Пионер сабан туе оештыра идек. «Тамчы» бию түгәрәге оештырдым. Укучылар белән мәктәптә дә, клубта да, хәтта район сәхнәләрендә дә чыгыш ясарга туры килде.

Пионер минем өчен мәңгелек оешма, изгелек, чын фидакарьлек орлыклары тәрбияли торган чиста башлангыч булып калачак.

**Шәхси архивыннан истәлекләр**



Пионервожатый булып эшләгән еллар бик тә сагындыра



“Тамчы” бию түгәрәге кызлары: Әхмәдиева Гүзәл һәм Титова Римма





1989 ел. Пионер сабан туеннан күренешләр. Ягез, кем өлгер, кем җитез?



Минем  беренче укучыларым

